СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

**28 октябрь 2021 ел** **№ 35**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Наласа авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 96 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы Шакирова И.Р

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге Советының
28 октябрь 2021 ел, №35
карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында
# Нигезләмә

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә эшләнде.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында әлеге торак пунктта яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган даими яисә башлыча әлеге территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ихтыяри һәм ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены турыдан-туры җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында үткәрелә.

1.6. Гражданнар җыенында әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысыннан артыгы бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены Устав нигезендә этаплап үткәрелә.

## Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

1) күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерә торган, составына күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) җирлек составына керә торган торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

3) Татарстан Республикасы законы нигезендә торак пункт территориясе өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирлек составына керүче торак пункт территориясе өлешендә;

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннән чыгып, җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

4) торак пунктта инициатив проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча.

5) муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазифасын биләүгә конкурс уздырганда конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында.

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү**

1.8. Җыенны уздыру җирлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Җыенны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чыгымнар җирлек бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

**Гражданнар җыенын уздыру инициативасы**

2.1. Торак пунктта гражданнар җыенын үткәрү инициативасы белән түбәндәгеләр чыга:

- җирлек башлыгы;
- сайлау хокукына ия, гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган торак пунктта (яисә аның территориясенең бер өлешендә) яшәүчеләрнең 10 кешедән дә ким булмаган төркеме ягъни яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән, даими яки башлыча торак пункт территориясендә яшәүче, хокукка сәләтле гражданнар, шулай ук торак пункт территориясендә даими яисә башлыча яшәүче һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия чит ил гражданнары.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативасы имзалар кәгазьләре рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш. Анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителгән сроклары;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаган һәр гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, яшәү урыны адресы, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры; аның имзасы һәм имзасын кую датасы.

2.3. Җыен үткәрү инициативасын хуплап җыярга кирәк булган имзалар саны торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия даими яисә башлыча яшәүче гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, әмма 10 имзадан да ким була алмый.

2.4. Имзалар кәгазьләре имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан таныклау датасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, паспортының яисә аны алмаштыручы документының номерын һәм сериясен, яшәү урыны адресын күрсәтеп таныклана һәм җирлек башлыгына җибәрелә.

**Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе**

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены җирлек Советы карары (2 нче кушымта) белән, ә җирлек башлыгы инициативасы белән чакырыла торганы җирлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) кирәкле барлык документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Җирлек башлыгы яки җирлек Советы гражданнар җыенын үткәрүдән максатка ярашсызлыгы мотивлары буенча баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына (гражданнар җыенының этапларына) чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыены мәсьәләсе аны төрлечә аңларлык итеп формалаштырылмаска тиеш, ягъни аны бер төрле мәгънәдә генә аңлап булырга тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) турында җирлек уставында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җирлек башлыгы карарында яисә гражданнар җыенын уздыру турында җирлек Советы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы җирлекнең башкарма комитеты турында белешмәләр.

2.9. Җыенны оештыручы җирлек башлыгы карары яки җирлек Советының гражданнар җыенын үткәрү турындагы карары нигезендә сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең исемлекләрен төзи; халык җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итә (4 нче кушымта).

Гражданнар җыенын оештыручы гражданнар җыенын уздыру өчен бина бирергә тиеш.

2.9.1. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда торак пунктта яшәүчеләр исемлеген бүлү һәм гражданнар җыенын уздыру датасын билгеләү территориаль, вакыт ягыннан, шулай ук башка очракларда мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләр исемлеген бүлү тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта (5,6 нчы кушымталар) күрсәтелә.

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләргә гражданнар җыенының (гражданнар җыены этаплары) вакыты һәм уздыру урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) билгеләү, гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) уздыру вакыты һәм урыны турындагы карар гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Гражданнар җыены этапларын уздыру вакыты һәм урыны гражданнар җыенын билгеләү турындагы бер карарда күрсәтелә.

2.9.4. Гражданнар җыены этаплап үткәрелгән очракта, җыен гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта этаплап уздырыла. Гражданнар җыены этаплары күчерелгән очракта,

гражданнар җыенын күчерү турындагы карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча һәм законнар нигезендә җыен үткәрелергә тиешле бер ай вакытны исәпкә алып кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Гражданнар җыенында катнашучы һәр кеше җыенны үткәрү датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча җыенны оештыручыда гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәләрен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә гражданнар җыенын уздыру датасы соңрак вакытка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын күчерү турындагы карар җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

**3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе**

3.1. Җыенга килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия җыенда катнашучы затларны теркәү өчен җирлек башлыгы вәкаләт биргән зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы, паспортының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенга шулай ук хәлиткеч тавыш хокукыннан башка җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнар, җыенда тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлеге белән бәйле булган оешма, предприятие җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3.3. Торак пунктта сайлау хокукына ия яшәүчеләр исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче җирлек башлыгы тарафыннан теркәлергә һәм анда катнашуга кертелергә мөмкин.

3.4. Гражданның шәхесен раслый торган документ булу (Россия Федерациясе гражданы паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүгә рөхсәт бирү һ.б.) язмаларның төгәлсезлеген раслый ала.

3.5. Гражданнар җыены анда торак пунктта (территориясенең бер өлешендә) яисә җирлектә яшәүче сайлау хокукына ия затларның яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы. Кворум булмаганда, гражданнар җыенын уздыруның яңа датасын билгеләү җирлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта, гражданнар җыены гражданнар җыенын уздыру билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелмәскә тиеш.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыены, барлык уздырылган этаплар нәтиҗәләре буенча тавышларны санап, җыенның этапларына гражданнар теләсә нинди санда килүләренә карамастан хокуклы, ягъни җыен бер булып санала.

3.7. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык рәвештә алып барыла.

3.8. Гражданнар җыенында җирлек башлыгы яисә җыенда теркәлгән катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.9. Гражданнар җыены секретарь һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап

комиссиясе әгъзалары саны өч кешедән дә ким була алмый.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) торак пунктта яисә аның территориясенең бер өлешендә яшәүчеләрне теркәүнең дөреслеген, аларның гражданнар җыены эшендә катнашу хокукын тикшерә;

2) гражданнар җыенының кворумын билгели (гражданнар җыенын этаплап уздыру очракларыннан тыш);

3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

4) тавышларны саный һәм тавыш бирү буенча йомгак (гражданнар җыенын этаплап уздыру очракларыннан тыш) ясый;

5) тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи (гражданнар җыены йомгаклары буенча);

6) рәислек итүче материалларны тавыш бирү нәтиҗәләре белән (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.

3.10. Өстәмә сораулар гражданнар җыенының көн тәртибенә рәислек итүче, җирлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукы булган гражданнар тарафыннан кертелергә мөмкин. Гражданнар җыены инициаторлары керткән мәсьәләләр көн тәртибенә мәҗбүри рәвештә кертелә. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта карала. Өстәмә мәсьәләләрне гражданнар җыенының көн тәртибенә кертү турындагы карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.11. Гражданнар җыенын этаплап үткәргәндә җирлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән гражданнар җыенында катнашучылар саныннан гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатурасын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.12. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда ачык тавыш бирү башкарыла.

3.13. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда, гражданнар җыенының һәр этабында кворум һәм йомгаклау тавышларын санаганда ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча комиссия составында эшләячәк хисап комиссиясеннән берәр әгъза сайлана.

3.14. Гражданнар җыенын җыенда рәислек итүче ача. Рәислек итүче гражданнар җыенын уздыруны оештыра, тәртип тәэмин итә, хисап комиссиясе эшен координацияли, фикер алышына торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, билгеләнгән тавыш бирү тәртибен тәэмин итә.

3.15. Гражданнар җыенында секретарь тарафыннан беркетмә алып барыла, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышнарның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (7 нче кушымта).

3.16. Гражданнар җыенын этаплап уздырганда гражданнар җыенының һәр этабында беркетмә (8, 9 нчы кушымталар) алып барыла, алар алга таба гражданнар җыенының уздырылган этаплары нәтиҗәләре буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсе (10 нчы кушымта), шулай ук хисап комиссиясе

беркетмәсе (11,12 нче кушымта) рәсмиләштерелә, алар шулай ук гражданнар җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә рәсмиләштерелә (13 нче кушымта).

3.17. Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында белешмәләр, көн тәртибе, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турындагы күрсәткечләр, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре турында белешмәләр була. Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куйган халык җыены карарын рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен нигез булып тора.

3.18. Беркетмәгә җыенда рәислек итүче зат, җыен секретаре имза куя һәм җирлек башлыгына тапшыра. Беркетмәгә җыенда теркәлгән катнашучыларның исемлеге кушып бирелә.

3.19. Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары йомгаклары буенча хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыенын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, җыенның көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, гражданнар җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыен үткәрү өчен билгеләнгән территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашучы гражданнарның гомуми саны, җыенда хуплап яки каршы бирелгән тавышларның гомуми саны күрсәтелә.

3.20. Йомгаклау беркетмәсенә хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары имза куя һәм җирлек башлыгына тапшыра.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Әгәр гражданнар җыены карары өчен гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучыларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, җирлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазифаи затлары, алар арасында җирлек уставында билгеләнгән вәкаләтләр бүленү нигезендә, гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итә.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыенда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яисә үзгәртелергә мөмкин яисә суд тәртибендә гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) һәм муниципаль хокукый актлар таләпләре нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш.

4.6. Әгәр торак пунктта яки аның территориясенең бер өлешендә яшәүчеләрнең турыдан-туры ихтыяр белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (бастырып чыгару) таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (бастырып чыгару) керә торган җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазифаи заты гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә

кергән көннән алып 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан арта алмый.

**Гражданнар җыены карарларын үтәү**

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә яки аның территориясенең бер өлешендә һичшиксез үтәлергә тиеш һәм дәүләт хакимияте органнары, аларның вазифаи затлары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Имзалар кәгазе**

Без, түбәндә кул куючылар, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең ________ торак пунктында түбәндәге сораулар буенча (гражданнар җыенын уздыру сроклары) гражданнар җыенын үткәрү инициативасын хуплыйбыз:_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

| N | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туу датасы | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе, номеры | Имза кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имза кәгазен таныклыйм:________________________________________________
(имзалар җыюны гамәлгә ашыручы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне,яшәү урыны, паспортының яисә аны алыштыручы документының сериясе һәм номеры)
_______________________________________________________________

(имза һәм дата)

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**_________ 20** ел** **№___**

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең _____________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Наласа авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге ____________ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ____________________________________________________________________ адресы буенча _______ 20 * _________ 00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________ торак пунктында теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, _______________________________________________ тыш, _____сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
________________________________________?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына __________________________________________, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында _________ буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң ______ көн эчендә халыкка җиткерергә һәм __________________________________________ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге Советы рәисе
______________________

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
3 нче кушымта

СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа
авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**_________ 20** ел** **№___**

**“Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең _____________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _____________ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ______________________________________________________________________________ адресы буенча _______ 20 * _________ 00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________ торак пунктында теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, _______________________________________________________________ тыш, _____сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
________________________________________?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ______________________________________, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында ________ буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң _____ көн эчендә халыкка җиткерергә һәм ______________________________________ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында  Нигезләмәгә
4 нче кушымта

"___" __________________ 20_______ елга **Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге ________________ торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләр**

| N N пп | Исеме, фамилиясе, атасының исеме | Туган елы (18 яшь тулган булса - туган ае, көне) | Яшәү урыны адресы | Паспорт сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| .и | | | | | |
| 1 | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче_____________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

Гражданнар җыены секретаре      ______________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

.

Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
5 нче кушымта

СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**_________ 20** ел** **№___**

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең _____________торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Наласа авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге ____________ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын ______________________________________________________________
____________ адресы буенча _______ 20 * _________ 00 сәгатькә билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге ____________ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын ______________________________________________________________
____________ адресы буенча _______ 20 * _________ 00 сәгатькә билгеләргә.
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне ____________ (территориаль, вакыт буенча яки башкача) башкарырга.
   1 этап:
   2 этап:

4. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________ торак пунктында теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, _______________________________________________________________ тыш, _____сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме: ______________________________________________________________

______________________________________________________________________________
_____________________________________?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге _________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ___________________________________, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында ________ буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң _____ көн эчендә халыкка җиткерергә һәм ___________________________________ бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге Советы рәисе
____________________

.

Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
6 нчы кушымта

СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башлыгы карары**

**№**

**"Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең_____________ торак пунктына гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге ____________ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын ______________________________________________________________
____________ адресы буенча _______ 20 * _________ 00 сәгатькә билгеләргә.
2.Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге ____________ торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын ______________________________________________________________
____________ адресы буенча _______ 20 * _________ 00 сәгатькә билгеләргә.
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне ____________ (территориаль, вакыт буенча яки башкача) башкарырга.
1 этап:
2 этап:

4. Гражданнар җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 20__ елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________ торак пунктында теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, ________________________________________________________________ тыш, _____сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

_________________________________________?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

5. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге __________ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ________________________________________, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы рәсми сайтында _________ буенча урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң ______ көн эчендә халыкка җиткерергә һәм ________________________________________ бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
7 нче кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

____________________________________________________________

(торак пункт исеме)
"___" _____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут N _____

Катнашты ________________________________________________ кеше

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче___________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены секретаре ____________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

КӨН ТӘРТИБЕ:

1.

2.

ҖЫЕННЫҢ РӘИСЕ САЙЛАНА:

1. __________________________ - _____________________

ФИАи, вазифасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап ___________кеше
Каршы ______________ кеше.

ҖЫЕН СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:
Рәислек итүче: җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак-

ФИАи-вазифага җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап ___________кеше
Каршы ______________ кеше.

ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен ясау, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп __________________ФИАи, вазифасы һәм хисап комиссиясе әгъзаларын: ФИАи-вазифасы, ФИАи вазифаны сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

Беренче сорау буенча тыңладылар:________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(кыскача чыгыш яисә доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучылар саны буенча).

Карар бирделәр: (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.
Карар _________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар: ____________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(кыскача чыгыш яисә доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

Карар иттеләр: (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше

Каршы _____________ кеше.
Карар ________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________

(имза) ( тулы имза)

Гражданнар җыены секретаре _________ _________________

(имза) ( тулы имза)

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
8 нче кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ 1 ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ

_______________________________________________________________

(торак пункт исеме)

"___" _____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут N _____

Катнашты ________________________________________________ кеше

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче__________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены секретаре ____________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

КӨН ТӘРТИБЕ:

1.

2.

ҖЫЕННЫҢ РӘИСЕ САЙЛАНА:

1. __________________________ - _____________________

ФИАи, вазифасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

ҖЫЕН СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:
Рәислек итүче: җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак-

ФИАи-вазифага җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен ясау, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп __________________ФИАи, вазифасы һәм хисап комиссиясе әгъзаларын: ФИАи-вазифасы, ФИАи вазифаны сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:_______________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(кыскача чыгыш яисә доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучылар саны буенча).

Карар бирделәр: (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.
Карар ________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар: ___________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(кыскача чыгыш яисә доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

Карар иттеләр: (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.
Карар ________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________

(имза) ( тулы имза)

Гражданнар җыены секретаре _________ _________________

(имза) ( тулы имза)

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
9 нчы кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ 2 ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ

____________________________________________________________

(торак пункт исеме)

"___" ____________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут N _____

Катнашты ________________________________________________ кеше

(торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында рәислек итүче___________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены секретаре ____________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

КӨН ТӘРТИБЕ:

1.

2.

ҖЫЕННЫҢ РӘИСЕ САЙЛАНА:

1. _________________________ - ____________________

ФИАи, вазифасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

ҖЫЕН СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА:
Рәислек итүче: җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак-

ФИАи-вазифага җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: халык җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен ясау, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе итеп __________________ФИАи, вазифасы һәм хисап комиссиясе әгъзаларын: ФИАи-вазифасы, ФИАи вазифаны сайлау тәкъдиме бар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.

КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар:_______________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(кыскача чыгыш яисә доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучылар саны буенча).

Карар бирделәр: (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше
Каршы _____________ кеше.
Карар ________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар: ____________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(кыскача чыгыш яисә доклад тексты (кушымта итеп бирелә)

Чыгыш ясадылар: 1. ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача язмасы яки чыгыш тексты (кушымта итеп бирелә)
һ. б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

Карар иттеләр: (карар эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
Хуплап __________кеше

Каршы _____________ кеше.
Карар ________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _________ _________________

(имза) ( тулы имза)

Гражданнар җыены секретаре _________ _________________

(имза) ( тулы имза)

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
10 нчы кушымта

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ҮТКӘРЕЛГӘН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ БЕРКЕТМӘСЕ

_______________________________________________________

( Татарстан Республикасы _______муниципаль районының _ торак пункты исеме)
"__" _________ 20__ ел 00 сәгать 00 минут N __

____ 20__ ел, № 1 беркетмә нигезендә, беренче этабы (рәислек итүче ФИАи), ____ 20__ ел, № 2 беркетмә икенче этабы (рәислек итүче ФИАи) __________________________________________________________________ мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыеннары үткәрелде.

1.Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары саны______.

2. Гражданнарның җыенының этаплары беркетмәләре саны ____ .

3. Җыен үткәрү өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аларның эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны __________;

4. Сайлау хокукына ия һәм җыен этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны___________.

Карар иттеләр: (карар эчтәлеге)

- Җыен этапларында кертелгән сорау (лар) өчен хуплап бирелгән тавышларның гомуми саны _________;

- Кертелгән сорауга (ларга) "Каршы" бирелгән тавышларның гомуми саны _______;

Карар: кабул ителде (кабул ителмәде, сәбәпләрен күрсәтеп)
Рәислек итүче

(Җирлек башлыгы): _________ ____________________

(имза) ( тулы имза)

Секретарь: _________ ______________________

(имза) ( тулы имза)

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
11 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге составына керүче ________________________ торак пунктта тавыш бирү нәтиҗәләре турында гражданнар җыенының беренче этабы хисап комиссиясе беркетмәсе**

"_____" ________ 20 ел N 1

Хисап комиссиясе әгъзалары катнаша:

1. ФИАи;

2. ФИАи;

3. ФИАи;

һ.б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукы булган______________ граждан катнашты.
Гражданнар җыенының беренче этабының көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү йомгаклары:

хуплап____________тавыш

каршы_________тавыш

Хисап комиссиясе рәисе ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИАи

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
12 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге составына керүче ___________________ торак пунктта тавыш бирү нәтиҗәләре турында гражданнар җыенының икенче этабы хисап комиссиясе беркетмәсе**

"_____" ________ 20 ел N 1

Хисап комиссиясе әгъзалары катнаша:

1. ФИАи;

2. ФИАи;

3. ФИАи;

һ.б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукы булган______________ граждан катнашты.

Гражданнар җыенының беренче этабының көн тәртибе мәсьәләсе буенча тавыш бирү йомгаклары:

хуплап____________тавыш

каршы_________тавыш

Хисап комиссиясе рәисе ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИАи

.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
торак пунктларында гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү
тәртибе турында Нигезләмәгә
13 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче_______ торак пунктта тавыш бирү нәтиҗәләре турында гражданнар җыенының беренче, икенче (һ.б.) этабы хисап комиссиясе беркетмәсе**

"_____" ________ 20 ел N ____

Гражданнар җыенының беренче, икенче (һ. б.) этапларының тавыш бирү нәтиҗәләре ____________________________________________________________________

(муниципаль берәмлек яки аның өлеше территориясе исеме)

____________________________________________________________________

Гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы һәм вакыты: _______________ 20__ ел
Гражданнар җыеннарында тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә:

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

Хисап комиссиясе билгеләде:

1. Гражданнар җыенында үткәрелгән этаплар саны ___________________.
2. Гражданнар җыенының үткәрелгән этапларының хисап комиссиясе беркетмәләре саны _______;

3. Җыен үткәрү өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны__________;

4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________________;

5. Халык җыенына кертелгән сорауны хуплап бирелгән тавышларның гомуми саны _______;

6. Гражданнар җыенына кертелгән сорауга каршы бирелгән тавышларның гомуми саны _______;

Карар бирделәр:

1. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә __________ мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга җыенның _________________ мәсьәләсе буенча карарын кабул ителгән дип санарга.
Хисап комиссиясе рәисе ФИАи

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИАи

Беркетмә 20___ елның ______________ төзелде.